СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423740,село Актаныш, проспект
Ленина, дом 58, тел. 3-44-40

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АКТАНЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
423740, Актаныш авылы, Ленин
проспекты, 58 нче йорт, тел. 3-44-40

# КАРАР

**30 сентябрь 2024 ел** **№11**

Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 10 июнендәге 7 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Актаныш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Актанышбаш авыл җирлеге советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Актаныш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 10 июнендәге 7 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктның 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

"1,2% нисбәттә Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән 1000 квадрат метрдан артык гомуми мәйданы булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар).».

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүматы порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә урнаштырырга.

**Актаныш авыл җирлеге башлыгы- Совет рәисе** **Л.Р.Зарипов**